КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2019 ел, 7 ноябрь г.Казань № 1022

2019 – 2020 елларда Балачак унъеллыгы кысаларында үткәрелә торган Татарстан Республикасы чаралары планын тормышка ашыру буенча чаралар комплексы турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә Балачак унъеллыгын игълан итү турында» 2017 елның 29 маендагы 240 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2019 – 2020 елларда Балачак унъеллыгы кысаларында үткәрелә торган Татарстан Республикасы чаралары планын (алга таба – Балачак унъеллыгы чаралары планы);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы 2019 – 2020 елларда Балачак унъеллыгы кысаларында үткәрелә торган Татарстан Республикасы чаралары планын тормышка ашыру буенча яраштыру советы турындагы нигезләмәне;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы 2019 – 2020 елларда Балачак унъеллыгы кысаларында үткәрелә торган Татарстан Республикасы чаралары планын тормышка ашыру буенча яраштыру советы составын;

Балачак унъеллыгы кысаларында үткәрелә торган массакүләм чаралар планын (алга таба – Массакүләм чаралар планы).

2. Балачак унъеллыгы чаралары планын һәм Массакүләм чаралар планын тормышка ашыру өчен җаваплы итеп Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең җаваплы үтәүчеләре булган башкарма органнарына:

Балачак унъеллыгы чаралары планын һәм Массакүләм чаралар планын үтәүне тәэмин итәргә;

ярты елга бер тапкыр, хисап чорыннан соң килә торган айның 15енә кадәр, Балачак унъеллыгы чаралары планын һәм Массакүләм чаралар планын тормышка ашыруның барышы турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына мәгълүмат кертергә.

4. Федераль башкарма хакимият органының җаваплы үтәүчесе булган территориаль органына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Балачак унъеллыгы чаралары планын һәм Массакүләм чаралар планын үтәүне тәэмин итүне;

ярты елга бер тапкыр, хисап чорыннан соң килә торган айның 15енә кадәр, Балачак унъеллыгы чаралары планын һәм Массакүләм чаралар планын тормышка ашыруның барышы турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына мәгълүмат кертүне.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына бу карарның 3, 4 нче пунктлары нигезендә алынган мәгълүматны гомумиләштерергә һәм ярты елга бер тапкыр, хисап чорыннан соң килә торган айның 30ына кадәр, аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына 2019 – 2020 елларда Балачак унъеллыгы кысаларында үткәрелә торган чараларның муниципаль планнарын Балачак унъеллыгы чаралары планына туры китерүне тәкъдим итәргә.

7. Балачак унъеллыгы чаралары планын һәм Массакүләм чаралар планын финанслау тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең җаваплы үтәүчеләре булган башкарма органнарына карала торган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин